**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 16 гыйнвар № 10

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2014 ел, 8 октябрь, 733 нче; 2015 ел, 7 август, 574 нче; 2016 ел, 1 сентябрь, 608 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 нче пунктның 1 пунктчасына «, файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләренең чикләре үзгәргәндә бер тапкыр түләнә торган түләүләрне кертеп;» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 20.1 нче пункт өстәргә:

«20.1. Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар лицензия иясе гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен файдалана торган эчке елга һәм катнаш («елга-диңгез») йөзү судноларын ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы аша Татарстан Республикасының бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыруны тәэмин итәргә тиеш.»;

28 нче пунктның алтынчы абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«, дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Россия Федерациясе законнары;»;

29 нчы пунктның тугызынчы абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«, «Җир асты байлыклары турында» 1992 ел, 21 февраль, 2395-I Россия Федерациясе Законының 27 статьясы нигезендә федераль геологик мәгълүмат фондына һәм «Идел буе федераль округы буенча территориаль геологик мәгълүмат фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалына, шулай ук Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондына (җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләргә карата) җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны тапшырмау яки тапшыру вакытларын бозу;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\10.docx